Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

2 октябрь, 2024 ел № 2

Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Пановка авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 138/92 номерлы (2021 елның 14 декабрендәге 32 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) Пановка авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Пановка авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Пановка авылында гражданнар җыены өч этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2024 елның 16 октябрендә 15.00 сәгатьтә Мәктәп урамы, 2А йорт адресы буенча күпфункцияле үзәк бинасында янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яшел, Мусин, Беренче Май урамнары, Үзәк урамы 1-14 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2024 елның 16 октябрендә 16.00 сәгатьтә Мәктәп урамы, 2А йорт адресы буенча күпфункцияле үзәк бинасында янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Үзәк урамы 16 - 31 йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының өченче этабы 2024 елның 16 октябрендә 17.00 сәгатьтә Мәктәп урамы, 2А йорт адресы буенча күпфункцияле үзәк бинасында

янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Яңа, Тукай, Мәктәп урамы йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2025 елда Пановка авыл җирлеге Пановка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Чернобыль АЭСдәге аварияне бетерүдә катнашучыларны, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрне, 2 группа эшләмәүче инвалидларны, сугыш һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарын, Чернобыль АЭСдәге аварияне бетерүдә катнашучыларны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларн бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- торак пункт территориясен төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Новоселок авылында гражданнар җыены уздырырга:

- гражданнар җыенын 2024 елның 16 октябрендә 18.00 сәгатьтә Мәктәп урамы, 2А йорт адресы буенча күпфункцияле үзәк бинасында янында үткәрергә.

«Сез, 2025 елда Пановка авыл җирлеге Пановка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Чернобыль АЭСдәге аварияне бетерүдә катнашучыларны, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрне, 2 группа эшләмәүче инвалидларны, сугыш һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарын, Чернобыль АЭСдәге аварияне бетерүдә катнашучыларны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларн бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- торак пункт территориясен төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Пановка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге башлыгы О.И. Козырев